**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге башлыгы карары**

**2022 елның 11 ноябре** **№ 2**

**«Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1 2022 елның 22 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Кече Чура авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча Кече Чура авылы клубы бинасында үткәрергә.

2 2022 елның 22 ноябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Югары Чура авыл җирлегенең Кече Чура авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

Гражданнар җыенын Кече Чура авылы, Мәктәп урамы, 2 нче йорт адресы буенча Кече Чура авылы клубы бинасында үткәрергә.

3 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Югары Чура авыл җирлеге Кече Чура авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; шулай ук Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Кече Чура авылының Яшел, Мәктәп урамнарындагы юлларга вак таш җәю (вак таш сатып алу, ташу, җәю); проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылы Мәктәп, Тукеев Федот урамнарына вак таш җәеп, юлларда чокырларны ремонтлау; проект-смета документларны эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылында урамнарны яктырту өчен энергия саклаучы лампалар сатып алу, урнаштыру, яктырткычларны, махсус җиһазларны ремонтлау; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылының Мәктәп урамына юл билгеләре сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылында Бөр елгасы җәяүлеләр чыгу юлын ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылы зиратын коймалау өчен материал сатып алу; килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Кече Чура авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан чистарту һәм территорияне җәй көне чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Кече Чура авылындагы балалар һәм спорт уен мәйданчыкларын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Кече Чура авылы урамнарында коры агачларны һәм куакларны кисеп ташлау, кисү, төпләү һәм санитар эшкәртү; махсус техника яллау; проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру; килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

- Кече Чура авылына видеокамералар сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эш һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү;

- Кече Чура авылының Яшел урамына асфальт җәю һәм вак таш җәеп ремонтлау; проект-смета документларын эшләү һәм экспертиза, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;

«РИЗА» «КАРШЫ».

4. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

5. Халык җыеннын үткәрүгә җаваплы итеп Югары Чура авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Югары Чура авыл җирлеге башлыгы В.Н. Андреев